БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» 07 2024 ел № 193

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2024 елның 14 февралендәге 81 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында "2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 21 июнендәге 447 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2024 елның 14 февралендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 81 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Балтач муниципаль районында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәне кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Балтач муниципаль районының муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләмен саклап калу һәм шул ук квалификациядәге эшләрне башкару шарты белән, әлеге карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкән вакытка гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан кимрәк була алмый, дип билгеләргә.

3. Балтач муниципаль районының муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле профсоюз берлекләре органы белән килештереп:

Балтач муниципаль районының муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгеләү торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

Балтач муниципаль районының муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә җитди хезмәт шартларының үзгәрүе турында хәбәр итәргә.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов